**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ**
**РАЙОНЫ БАШКАРМА**
**КОМИТЕТЫ**
**422700, Биектау тимер юл станциясе**
**поселогы Кооператив урамы, 5**
**тел. 2-30-61, факс 2-30-86**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**422700, пос.ж/д ст.Высокая Гора**
**ул.Кооперативная, 5**
**тел. 2-30-61, факс 2-30-86**

КАР АР **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

*29.01.2008* № *64*

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең "Челтәр компаниясе" ААҖ карамагындагы электр тапшыру һава линияләренең саклау зоналары чикләрен раслау һәм саклау зоналары чикләренә керә торган җир кишәрлекләренә хокукларны чикләүне билгеләү турында" 2008 елның 29 гыйнварындагы 64 номерлы карары**

"Челтәр компаниясе" ачык акционер җәмгыятенең Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында урнашкан 1000 В дан артык көчәнешле һава электр тапшыру линияләренең саклау зоналары чикләрен раслау һәм һава электр тапшыру линияләренең саклау зоналарына керә торган җир кишәрлекләренә хокукларны чикләүне билгеләү турындагы мөрәҗәгатен, шулай ук саклау зоналары чикләрен билгеләү буенча "Республика мониторинг һәм җир төзелеше үзәге" ҖЧҖ тарафыннан башкарылган материалларны карап, электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының имин һәм авариясез эшләвен тәэмин итү, имин эксплуатацияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 56 статьясындагы 1 пункты нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирләрендә урнашкан, гомуми мәйданы 2860034,3 кв. м булган "Челтәр компаниясе" ААҖнә караган һава электр тапшыру линияләренең саклау зоналары чикләрен җир төзелеше материаллары нигезендә расларга (1 нче кушымта).

2. СССР Министрлар Советының 1984 елның 26 мартындагы 255 номерлы карары белән расланган "1000 в дан артык көчәнешле электр челтәрләрен саклау кагыйдәләре" нигезендә һава электр тапшыру линияләренең саклау зоналары чикләренә кергән җир кишәрлекләренә хокукларны (йөкләнешләрне) чикләүне билгеләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ю.С. Садреев

**1нче кушымта**
**ТР Биектау муниципаль районы Бшкарма комитеты**
**Җитәкчесенең 2008 елның 29 гыйнварындагы**
**64 номерлы карары белән расланды**

| № т/б | Һава ЛЭП исеме | ЛЭП линиясенең гомуми озынлыгы, км | Саклау зонасының гомуми мәйданы, кв.м |
|---|---|---|---|
| 1 | Дербышки ПСда Киндерле - отпайкалы Оптика 110 кВ ҺЛ (1 нче чылбыр) | 1,18 | 55066,7 |
| 2 | Киндерле - Оптика – Дербышки 110 кВ ҺЛ (2 нче чылбыр) | 1,32 | 64483,3 |
| 3 | Киндерле - Тяговая110 кВ ҺЛ | 0,90 | 45366,2 |
| 4 | Магистральная – Киндерле 110 кВ ҺЛ | 15,06 | 716873,0 |
| 5 | Магистральная – Киндерле220 кВ ҺЛ | 15,41 | 939055,5 |
| 6 | Киндерле - Үзәк 110 кВ ҺЛ | 16,26 | 775127,8 |
| 7 | Константиновка ПС 110 кВ ҺЛ отпайкасы Киндерле - Үзәк 110 кВ ҺЛнән оп. 24 кадәр | 3,99 | 194783,9 |
| 8 | Азино ПС 110 кВ ҺЛ отпайкасы Киндерле - Үзәк 110 кВ ҺЛнән оп. 24 кадәр | 1,46 | 69277,9 |
| | Барлыгы | 55,58 | 2860034,3 |